**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2019 елның 21 февраленнән №2-РС

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2018 ел өчен социаль-икътисади үсеше йомгаклары һәм 2019 елга төп бурычлары турында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына ярашлы төстә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы М.П.Афанасьевның “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2018 ел өчен социаль-икътисади үсеше йомгаклары һәм 2019 елга төп бурычлары турында”гы отчетынтыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль район Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Башлыкның “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2018 ел өчен социаль-икътисади үсеше йомгаклары һәм 2019 елга төп бурычлары турында”гы отчетын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының җирле үзидарә органнарына 2019 елга куелган бурычларны тормышка ашыру өчен кирәкле чаралар кабул итәргә һәм түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1) планлаштыру һәм икътисади үсеш өлкәсендә:

- районның халык тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлтелгән социаль-икътисади үсеше;
- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының авыл җирлекләрендә комплекслы сәнәгать мәйданчыклары булдыру, бизнес үсеше өчен оптималь шартлар тудыру, аерым алганда, районның сәнәгать мәйданчыкларында эшләү өчен резидентлар – күп санлы предприятиеләр җәлеп итү буенча эшне активлаштыру;
- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә тормышка ашырылучы инвестицион проектларны яклау;
- салым салына торган базаны киңәйтү өчен барлык чараларны күрергә, эш урыннары булдыру һәм саклау, салымнарны үз вакытында җыюны тәэмин итү;
- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының салым, финанс органнары, җирле үзидарә органнарының тармак бүлекләре, предприятие һәм

учреждениеләре белән барлык салымнарны максималь мобильләштерү буенча тыгыз хезмәттәшлек;

- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында иҗтимагый оешмалар һәм башка берләшмәләрне яклау проектын тормышка ашыруны дәвам итү;

- икътисади кризис белән бәйле төстә, финансларны экономияләү өлкәләрен төгәл билгеләү;

- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә икътисадның тотрыклы үсешен һәм социаль стабильлеген тәэмин итү Комиссиясе эшен көчәйтү һәм халыкка аның эшчәнлеге турында хәбәр итү;

- халыкның эш активлыгын күтәрү, федераль һәм республика грант программалары турында мәгълүмат бирү;

- бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү өлкәсен киңәйтү;

- бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану;

2) мәгариф өлкәсендә:

- төп гомуми белем бирү программалары буенча гомуми белем бирү сыйфатын күтәрү һәм өстәмә белем бирүне оештыру;

- балалар артыннан күзәтү һәм аларны карауны тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;

- чыгарылыш сыйныф укучыларын бердәм дәүләт имтиханына һәм төп дәүләт имтиханына әзерләү сыйфатын күтәрү;

- мәгариф учреждениеләре челтәрен модернизацияләү, белем бирү процессына заманча технологияләр кертүне дәвам итү;

- белем алуга хокукны тормышка ашыру өчен шартлар тудыру, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә мәгариф системасының нәтиҗәле эшләвен һәм үсешен тәэмин итү;

3) сәламәтлек саклау өлкәсендә:

- халыкка медицина хезмәте күрсәтү дәрәҗәсен күтәрү;

- авыруларны профилактикалау, сәламәт тормыш рәвешен пропагандалау буенча эшне дәвам итү;

- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районына җәлеп итү максаты белән медицина хезмәткәрләре өчен уңайлы шартлар тудыру;

4) архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә:

- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы торак пунктлары төзелешендә архитектур-планлаштыру карарлары сыйфатын күтәрү;

- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә торак төзелешен үстерү буенча планлаштырылган эшне дәвам итү;

- җирлекләрнең генераль планнарына, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү, шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә территориаль планлаштыру өлкәсендә башка документларны эшләү һәм раслау буенча эшне дәвам итү;

5) җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә:

- җир участоклары бүлеп биргәндә җир законнары таләпләрен үтәү;

- җир участокларын һәм муниципаль милекне арендалау буенча бурычлылар белән эшне активлаштыру;

- муниципаль җир контролен башкару;

- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә инвалидларга һәм составында инвалидлар булган гаиләләргә җир участокларын беренче чиратта бирү буенча эшне оештыру;

- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә закон тарафыннан билгеләнгән белгечлекләр буенча эшләүче гражданнарга бушлай файдалануга җир участоклары бирү буенча эш оештыру;

6)торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә:

- коммуналь челтәрләрнең искеләрен яңарту һәм яңаларын төзүне гамәлә ашыру;

- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы торак пунктларына асфальт юллар төзү буенча эшләрне дәвам итү;

- торак фондын капиталь ремонтлау буенча адреслы муниципаль программаны тормышка ашыру;

- район торак пунктларын төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча эшләр үткәрү;

- җирлекләр территорияләрендә законсыз чүплекләрне булдырмау;

- халыкны төзекләндерү мәсьәләләрен хәл итүгә җәлеп итү;

7) халыкны социаль яклау өлкәсендә:

- аерым категория гражданнарның тормыш дәрәҗәсен күтәрү;

- аз тәэмин ителгән һәм өлкән яшьтәге гражданнарга, инвалидларга ярдәм күрсәтүгә коммерциячел оешмаларны, физик затларны, иҗтимагый оешмаларны, авыл хуҗалыгы предприятиеләрен җәлеп итү;

8) опека һәм попечительлек өлкәсендә:

- балигъ булмаган ятим балаларны гаиләне алыштыручы гаиләләргә урнаштыруда ярдәм күрсәтү;

- элек ата-ана хокуклары чикләнгән гаиләләргә рецидивны, балигъ булмаганнарны яңадан тартып алуны булдырмас өчен контрольлек итүне тормышка ашыру;

- ятим балаларга билгеләнгән торак биналар өчен коммуналь түләүләрне үз вакытында түләүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

9) яшьләр сәясәте һәм спорт өлкәсендә;

- киң халык катламнарын системалы төстә спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү;

- яшьләрнең антисоциаль тәртибен профилактикалау һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча эшне дәвам итү;

- яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча эшне активлаштыру;

-яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, шул исәптән район үзәгендә яшьләр ялын оештыру;

10) мәдәният өлкәсендә:

- мәдәният учреждениеләре күрсәтә торган хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү;

- районда актуаль мәдәни сәясәт формалаштыру, традицион халык һәм хәзерге заман мәдәниятен саклау һәм үстерү;

- «Каравон -2019» рус фольклоры фестивален лаеклы дәрәҗәдә үткәрү;
- мәдәният учрежденияләренең матди-техник базасын ныгыту буенча эшне дәвам итү;
- милли-мәдәни коллективлар эшен дәвам итү, дини конфессияләрнең толерантлык традицияләрен үстерүгә ярдәм итү;
- түләүле хезмәтләр исемлеген арттыру;
- киновидеоучреждение эшен активлаштыру;

11) мәгълүматлаштыру өлкәсендә:
- муниципаль хезмәтләрне электрон төстә күрсәтүнең сыйфатын күтәрү;
- муниципаль хезмәткәрләрнең мәгълүмати технологияләр өлкәсендә компетентлык дәрәҗәсен күтәрү;
- муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара хезмәттәшлек буенча эшне көчәйтү;

12) законлылык, хокук тәртибе һәм коррупция белән көрәш өлкәсендә:
- хокук бозуларны кисәтү, гражданнарның, җәмгыять һәм дәүләтнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү;
- террорчылык һәм экстремистлык белән көрәш буенча чараларны үтәү буенча эшне көчәйтү;
- коррупция тудыручы шартларга юл куймау;
- коррупциягә каршы иҗтимагый фикер формалаштыру;
- кадрлар хезмәтләре берләшмәләренең, коррупцион һәм башка җинаятьләрне профилактикалау өчен җаваплы затларның муниципаль хезмәттә хокуклар, бурычлар һәм чикләүләрне аңлату буенча профилактик эшен көчәйтү;
- этноконфессиональ мөнәсәбәтләр өлкәсендә һәм миграцион агымнарны къзщтеп торуда эшне көчәйтү;
- район территориясендә эшләнә торган хокук бозуларны кисәтү һәм булдырмау буенча идеологик һәм профилактик эшне көчәйтү;
- коррупция белән көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе эшчәнлеген һәм кадрлар хезмәтләре берләшмәләренең, коррупцион һәм башка җинаятьләрне профилактикалау өчен җаваплы затларның эшен көчәйтү.

3. Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы җирлекләре башлыклары белән берлектә гаилә терлекчелек фермалары булдыру һәм үстерү, шәхси хуҗалыкларга ярдәм итү һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы кешеләрен эшмәкәрлек һәм үзмәшгульлеккә җәлеп итү буенча эшне дәвам итәргә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

1) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2018 ел өчен социаль-икътисади үсеше йомгаклары һәм 2019 елга төп бурычлары турында фикер алышканда аталган бурычларны үтәүгә булышырга;

2) кешеләрнең проблемаларына үз вакытында игътибар бирергә һәм аларны хәл итәргә;

3) гражданнарга шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерүгә кредитлар алуда ярдәм итәргә;

4) җирлекләр территорияләрендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүдә актив катнашырга, шулай ук фермерларга республика һәм федераль программалар буенча грантлар алуда кирәкле ярдәм күрсәтергә.

5. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, дәүләт хакимиятенең территориаль башкарма органнары җитәкчеләренә, «Камская Новь» («Кама ягы») газетасына халыкка республиканың социаль-икътисади үсешенең өстенлекләре турында, республикада һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында үткәрелүче кризиска каршы чаралар һәм социаль программаларны тормышка ашыру турында мәгълүмат тапшырырга тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль район Советы Аппаратына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының отчет сессиясендә һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы халкы белән очрашуларда әйтелгән күрсәтмә һәм тәкъдимнәрне гомумиләштерергә.

7. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Башкарма комитетына йөкләргә: 2019 елның 1 апреленә кадәр тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

8. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).

9. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль район Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**